| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Крындинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кырынды авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2025 Кырынды авылы № 2-1

Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 ноябрендә кабул ителгән 53-2 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең бюджет кодексы нигезендә, 2025 елның 21 апрелендә кабул ителгән 84-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясенең Бюджет кодексына һәм "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен туктатып тору, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен гамәлдән чыгару һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын 2025 елда үтәү үзенчәлекләрен билгеләү" Федераль законының 14 һәм 15 нче статьяларына үзгәрешләр кертелү, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының 2025 елның 23 октябрендә кабул ителгән 02-08-01-2025/164 номерлы протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

2. 1.Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге Советының 2019 елның 26ноябрендә кабул ителгән 53-2 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 30 нчы маддәнең 5 нче өлешендә «муниципаль-шәхси партнерлык килешүләре» сүзләреннән соң «(публичный партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләре белән тулыландырырга;
1.2. 42 нче маддәне тугызынчы пунктны түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«9. Агымдагы финанс елында бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирүне таләп итә торган суд актларын үтәү (кешеләргә китерелгән зыянны компенсацияләү максатыннан чыгарылган суд актларыннан тыш), суд актында билгеләнгән максатларга туры килгән чыгым статьялары буенча бюджет турындагы закон (карар) белән каралган ассигнованиеләр чикләрендә башкарыла.».

Бу карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында, https://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча интернет челтәрендә урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегендәге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе
Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Мәүликәев